
Әхмәтгалиева, А. Кайнап яшибез / А. Әхмәтгалиева // Сәхнә. – 2022. – №12 (204). – Б. 16-17.



# КАЙНАП ЯШИБЕЗ!

Татарстан театрлары тамашачыларны яңа театраль сезонда каршы алды. Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театры 33 нче сезонны 9 сентябрьдә Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр» музыкаль комедиясе белән башлап җибәрде. Бу айлар дәвамында театр тамашачыларны премьералар белән дә, яңа проектлар белән дә сөендерде.



«Гаилә/театр» проекты зурлар өчен дә, балалар өчен дә күптән көтелгән бүләк икәнлеген раслады — кайтавазлар шуның дәлиле булып тора. Әти-әниләр зур залда спектакль караган мәлдә 5 яшьтән 10 яшькә кадәрге балалар анимацион театральләштерелгән программада катнаша ала, үз куллары белән рәсем ясыйлар, күңел ачалар, уйныйлар. Алар белән исә профессиональ аниматорлар шөгыльләнә. Мондый чара айга бер тапкыр үткәрелә.



Яңа проектның икенчесе «Театраль педагогика» дип атала. Аның төп максаты — шәһәребездә яшәгән яшь тамашачыны, укучыны, укытучыны татар театр сәнгатенә тагын да якынайту, артистлар, сәнгать җитәкчесе белән ачык диалог алып бару һәм татар халкының танылган язучылары, драматургларының әсәрләре белән таныштыру. Әлеге проект кысаларында иң башта Т. Миңнуллин драмасы буенча куелган «Без китәбез, сез каласыз» спектакле күрсәтелде. Спектакльдән



Фотолар А. Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының матбугат үзәгеннән алынды.

сонң фикер алышу, җанлы әңгәмә тамашачыларда зур кызыксыну уятты. Бүтенге көндә Кече залда барган «Хәл бу ки... Хәсән Туфан» драмасы (быелгы премьера) мәктәп укучылары арасында киң яңгыраш алып килә. Әлеге спектакльнең режиссёры һәм инсценировка авторы — Олег Кинҗәгулов. Театр бу сезонда «Хәл бу ки...» дип аталган поэтик-документаль спектакльләр сериясен чыгаруны күздә тоткан иде, аның беренчесе шагыйрь Хәсән Туфанның чынбарлыкка нигезләнгән тормыш мизгелләрен чагылдырды. Туфанның хатыны Луиза Салиәскәрованың дастаннарга тиң мәхәббәте, тугрылыгы һәм трагик язмышы спектакльнең буеннан-буена күзгә күренмәс җеп булып яктыртылды.



---

Алга таба һ. Такташ, Ф. Кәрим кебек шагыйрьләрнең иҗаты һәм язмышы турында спектакльләр чыгару күздә тотыла.

---

18 ноябрьдә тагын бер премьера — Аяз Гыйләҗевның «Баласын җуйган болан эзеннән» пьесасы буенча куелган «Болан» спектакле дөнья күрде. Болан — нәфис тә, сылу да, горур да булган гаҗәеп бер җан иясе. Ләкин әлеге атама кеше тәнендә төрле очракта төрле символик мәгънә ала... Пьеса геройларының кайберсе үткәненнән котылырга теләмичә мөгез каера; икенче берәве, бар җаваплылыкны бүтәннәр җилкәсенә аударып, болын-кырлар буйлап җилдерә; бик сирәкләр генә башкаларны һәм, иң мөһиме — үзен — кабул итәргә, аңларга, гафу итәргә сәләтле... Бу — гадәти драма гына түгел, ә ирония, юмор, гротеск белән сугарылган тамаша. 19 ноябрь көнне исә әлеге спектакль Татарстанның атказанган артисты Миләүшә Имамованың 50 яшьлек юбилее уңаеннан тәкъдим ителде.

---

Театр «Күңел» радиосы, «Чаллы ТВ», «ТНВ» телерадиокомпанияләре белән даими элемтәдә яши, тамашачылар безнең артистлар — Миләүшә Имамова, Фирдүс Сафин, Руслан Ибраһимов һәм театрның әдәби бүлек җитәкчесе Айгөл Әхмәтгалиеваны «Башваткыч» тапшыруында, Чулпан Арсланова, Руслан Әюпов һәм Марсель Мөсәвировны «Җырлыйк әле» тапшыруында күрергә өлгерделәр.

---

Афишалар, яңалыклар, «бу спектакльгә урыннар калмады» дигән — тамашачы өчен көенечле, артистлар өчен сөенечле белдерүләр, берсеннән-берсе җылы кайтавазлар, кыскасы, кайнап торган тормыш безнең социаль челтәрләрдә һәм театр сайтында даими яктыртылып килә. Ә күзгә-күз театр залларында очрашыйк!





Айгөл Әхмәтгалиева, театрның әдәби бүлек җитәкчесе



AnyScanner